Хәзерге вакытта лингвистикада тел һәм мәдәният мөнәсәбәтен милли үзенчәлекләр белән бәйләнештә тикшерүгә зур игътибар бирелә. Тел, шушы телдә сөйләшүче халыкның милли мәдәни хәзинәсе булып, анда халыкның иҗтимагый тормыш тәҗрибәсе туплана, эчке дөньясы һәм милли холык үзенчәлекләре чагыла. «Тел – этносның төп, ачык һәм тотрыклы күрсәткече» [1: 34].

Тел – милли мәдәният формалашуда иң мөһим элемент. Ул мәдәниятне бер мизгелгә генә чагылдырып калмый, аның элеккеге хәлен теркәп куя һәм кыйммәтен буыннан-буынга тапшыра. Сүзләр мәдәниятнең дәвамлылыгын һәм традицияләрнең бердәмлеген сакларга ярдәм итә. Телнең сүзлек составын төрле яклап өйрәнү филологиядә элек-электән мөһим мәсьәләләрдән саналды, шунлыктан аның белән кызыксынуларның кимегәне юк. Соңгы елларда тел белемендә мәдәни юнәлешләрдәге тикшеренүләр шактый артты, алар арасында этномәдәният лексикасын өйрәнүгә багышланганнары да шактый.

Телнең лексик байлыгын тулаем алып тикшерү гаять кыен һәм аны иңләп алу мөмкин дә түгел. Лексика телнең иң хәрәкәтчән өлкәләреннән саналганга күрә, «чорлар бәйләнешен» тәэмин итә: анда җәмгыятьнең элеккеге һәм хәзерге матди һәм рухи мәдәнияте турында мәгълүмат саклана.

Тел сүзлек байлыгының этномәдәният лексикасы дип аерылып карала торган катламы халыкның тарихи үсеше дәвамында тупланган төп мәдәни төшенчәләрне үз эченә ала. Соңгы елларда этномәдәни күренешләрнең атамаларын өйрәнүгә игътибар артуын билгеләп үтәргә кирәк. Бу мәкаләдә татар теленең этномәдәният лексикасының бер өлеше булган матди мәдәнияткә караган бер төркем берәмлекләргә күзәтү ясау максаты куела. Кешенең көнкүрешенә караган төп ихтыяҗлар ашау-эчү, кием, торак белән бәйле

булганлыктан, әлеге хезмәттә шулар белән бәйле күренешләр игътибар үзәгенә алына.

Этномәдәни лексиканың түбәндәге өлешләрен аерып карыйлар: «1) билгеле бер тел вәкилләре яши торган тирәлеккә хас табигать күренешләре атамалары; 2) матди мәдәният лексикасы; 3) рухи мәдәният лексикасы [2: 52]. Бу бүленештәге беренче төркем атамалар татар тел белемендә өйрәнелеп килә [3].

Матди һәм рухи мәдәният лексикасына килгәндә исә, фәндә аларны шартлы рәвештә генә аерып карыйлар. Ю.С.Степанов фикеренчә, «мәдәнияттә «чиста матди» һәм «чиста рухи» күренешләр юк» [4: 717]. Мәсәлән, матди мәдәният берәмлекләреннән ризыклар халыкның борын-борыннан килгән гореф-гадәтләренә, йолаларына бәйле, алар бу чараларның төп компонентларына әверелгән. Халык бәйрәмнәрендә милли киемнәрнең дә үз урыны бар. Димәк, тормыш-көнкүреш күренешләрендә матди һәм рухи мәдәниятнең берләшүе табигый хәл.

Матди һәм рухи мәдәният бер-берсе белән аерылгысыз бәйләнештә яшәсәләр дә, аларның һәркайсына хас үзенчәлекләре бар. «Матди мәдәният» атамасы культурология фәненә этнограф һәм антропологлар тарафыннан кертелә. Күпчелек галимнәр фикеренчә, «матди мәдәният» төшенчәсенә кешенең бөтен матди-гамәли эшчәнлек төрләре һәм аның нәтиҗәләре – төзелгән йортлар, эш кораллары, көндәлек тормыш кирәк-яраклары, кием-салым, савыт-саба һ.б. керә. Рухи мәдәният исә аң өлкәсен колачлап, фән, сәнгать, фәлсәфә, мәгърифәтчелек, дин, мифология һ.б. ларны үз эченә ала.

Матди мәдәниятнең элементлары, рухи мәдәният төрләреннән аермалы буларак, матди ихтыяҗларны канәгатьләндерә. Аларны барлыкка китереп, юкка чыгарып була; алар вакытлыча гына кулланылалар, ягъни вакытлар үтү белән искерәләр, тузалар. Матди кыйммәтләргә билгеле бер бәя куеп була, рухи күренешләрне исә сатып алып булмый.

Кешелек дөньясында, иң беренче чиратта, матди ихтыяҗлар туа. Вакытлар үтү белән, бу төр ихтыяҗлар канәгатьләндерелгәч кенә, кешегә рухи азык җитми башлый. Шулай итеп, төрле мифлар, фән, дин, сәнгать барлыкка килә.

Телдә матди һәм рухи кыйммәтләр үз урынын таба. Тел байлыгында ике мәдәният төренең лексемалары арасында гомумкешелек атамалары һәм милли уникаль концептлар күзәтелә. Матди лексикада *йорт, ишек, тәрәзә* һ.б. гомум атамалардан саналса, *түр, сәке, җилкапка* һ.б. татарларга хас милли үзенчәлекләрдән исәпләнә. Рухи кыйммәтләрдән фән, сәнгать, фәлсәфә өлкәсендә гомумкешелек терминнары өстенлек итсә, дини лексика һәм *күңел, рух* кебек сүзләр татар теленә генә хас.

Телнең сүзлек составы җәмгыятьтәге яңарышларга гаять сизгер. Теге яки бу күренешләрнең, предметларның кулланылыштан төшеп калуы яки, киресенчә, пәйда булуы телдә дә үзгәрешләр китереп чыгара. Төрле милләт кешеләренең бер-берсе белән тыгыз аралашып яшәве, глобальләшү, фән-техника үсеше һ.б. тәэсирендә телләрнең лексикасында гына түгел, ә халыкларның тормыш-көнкүрешендә дә охшашлыклар барлыкка килә. Әмма телнең сүзлек составында бер төркем сүзләр гасырлар буена кулланылышта яши, чөнки алар тормыш итү өчен мөһим, әһәмиятен югалтмый торган төшенчә-күренешләрне атыйлар. Әлеге тел берәмлекләре озын-озак тарихи юл үткән, аларның татар халык мәкальләрендә кулланылулары [5: 159], «Борынгы төрки сүзлек»тә теркәлүләре [6], төрки язма истәлекләрдә урын алулары [7], XVI йөз әдәби әсәрләрендә очраулары [8], XIX гасыр татар сүзлекләрендә бирелүләре [9] һ.б. менә шул хакта сөйли.

«Хәзерге глобальләшү чорында без телне үзеннән-үзе аңлашыла торган күренеш буларак кабул итәбез, еш кына аның бөтен халыкның кыйммәтле казанышы һәм мирасы булуын, аннан башка яшәү мөмкин түгеллеген онытабыз» [10: 320].

Көнкүреш лексикасы һәм матди мәдәният күренешләрен чагылдырган сүзләр күпмедер дәрәҗәдә туры килә. Теләсә кайсы телнең сүзлек составында әлеге халыкның тормыш-көнкүрешенә караган лексика шактый зур урын били. Нәкь менә аларда яшәү өчен иң мөһим предметлар һәм күренешләр ачык чагылыш таба.

Тарихта мәгълүм бер гыйбарә бар: үз милли традицияләрен хәтерләгән һәм саклаган халык гомерле һәм көчле була. Милләтне саклый торган шундый гореф-гадәтләрнең берсе ризык әзерләү һәм ашау культурасына карый.

Ризык – матди мәдәниятнең бер өлешен тәшкил итә һәм ул халыкның һөнәр-кәсебе, яшәү шартлары, тормыш тәҗрибәсе, байлыгы-муллыгы һ.б. белән бәйле. Теләсә кайсы илдә һәм теләсә кайсы чорда ашау-эчү традицияләре

матди мәдәниятнең иң тотрыклы элементларыннан санала. Татарлар – тарихи барышта табигый һәм иҗтимагый-икътисади шартлар йогынтысында шактый үзгәреш кичергән халык. Әлбәттә, бу милли ризыклар язмышына да тәэсир итми калмаган: күбесен әзерләү тәҗрибәсе буыннан-буынга күчми калган, кайберләре матди яктан яңа эчтәлек алган, чит халыклардан кергән ризыклар үзләштерелгән. Әмма татар халкының элек-электән килгән матди һәм рухи байлыгын үзләрендә саклаган ризыклары күп.

Татар тел белемендә ризык атамалары бер төркем галимнәрнең хезмәтләрендә гыйльми күзаллана. Т.Х.Хәйретдинова монографиясендә алар комплекслы рәвештә тикшерелә [11]; Г.Р.Мөгътәсимова хезмәтендә бу төркемгә караган искергән атамалар карала [12]; Ф.С.Баязитова җирле сөйләшләрдәге һәм әдәби телдәге ризык атамаларын халык традицияләренә бәйләп өйрәнә [13]; Ә.Ш.Юсупова XIX йөз татар сүзлекләрендәге ризык атамаларын барлый [9]; Р.Г.Мөхәммәдова мишәр татарларының ризыкларына тарихи-этнографик күзәтү ясый [14]; Р.Р.Җамалетдинов монографиясендәге сүзлек-белешмәлектә ризык атамаларына лингвомәдәни тасвирлама бирелә [15]; Ф.Х.Тарасова татар, рус һәм инглиз телләрендәге «ризык коды»н өйрәнә [16]. Р.Р.Җамалетдинов һәм Р.С.Нурмөхәммәтова төзегән «Татар теленең этнокультура сүзлегендә» 30лап татар милли ризыгы атамасы турында мәгълүмат китерелә [17]. XX-XXI гасыр сүзлекләре материалында татар телендәге ризык атамаларын өйрәнеп язылган хезмәтләрнең саны да шактый [18-20].

Татар халкының кулинария сәнгатенең тамырлары еракларга барып тоташа, шул сәбәпле «**азык-төлек**» тематик төркеме төрлелеге белән аерылып тора, аның үз эчендә дә берничә төркемчә бүлеп чыгарырга мөмкин.

1. Азык-төлекне гомумиләштереп атый торган сүзләр: *азык, аш, ашамлык, аш-су, кучтәнәч, сый, таба ашы, тәм-том* һ.б. Бу сүзләр арасында бер төркем ризыкларны гына гомумиләштереп атаучылары да бар: *таба ашы* сүзе табада пешерелә торган ашамлыкларны берләштерә, *тәм-том* баллы ризыкларны атый. Кунакка барганда, төрле ризыкларны *кучтәнәч*кә алырга була, тик шулай да, кешегә чәй ризыклары алып бару кабул ителгән. *Сый* сүзе дә гадәти генә ризыкларны атамый, ә кунак табынына куела торганнарын белдерә.

2. Шулпалар һәм аларны атый торган сүзләр: *салма, токмач, умач, чумар, шулпа, өйрә* һ.б. Шулпа һәм ашларны татар халкы элек-электән әзерли. Гадәти көннәрдә дә, кунак сыйлаганда да, татарлар табынга *шулпа* бирәләр. Авылларда исә ул төп ашамлык булып санала. Аңа *токмач* салып та, *умач* уып та, *чумар* белән дә, *ярма* салып, *өйрә* итеп тә пешерәләр. *Пилмән* дә, шулпасы белән бергә, беренче аш итеп бирелә.

3. Итле ризык атамалары: *билдәмә, бишбармак, дерелдәвек, ит, казылык, калҗа, койка, куллама, куырма, кыздырма, сукта, сызык, тулма, тутырма* һ.б. Алар, бердән, күчмә тормыш белән яшәгән бабаларыбыздан мирас булып калса, икенчедән, кырыс табигать шартларында яшәргә җайлашу өчен бик мөһим булган. Иттән аш, шулпа пешергәннәр. Ат итеннән гаять күп төрле ашлар әзерләгәннәр, кайберләрен исә аерым төр иттән генә пешереп булган. *Куллама* (итле салма), каклаган *казылык* татар ашлары арасында затлы ризыклардан саналган. *Куллама* белән *тулма*ны татар халкы хәзер дә бик яратып ашый. Ат эчәгесеннән *тутырма* (*сукта*) – эченә үпкә-бавыр белән төрле ярмалар салынган үзенчәлекле ризык әзерләгәннәр. Итне күп очракта пешереп кулланганнар, бик сирәк очракта, бәйрәм табынына гына кыздырып (*куырма, кыздырма, кәбаб*) биргәннәр. Хайванның баш-аяк итеннән *дерелдәвек, койка* ясаганнар. Кыскасы, татар халкы суелган малны тулаем файдаланып, аннан тәмле-тәмле ризыклар пешергән.

4. Сөт, йомырка ризыкларын белдерә торган сүзләр: *атланмай, йомырка, йомырка тәбәсе, каймак, катык, корт, кымыз, кәрчемә, май, сыр, сөзмә, сөт, тура, тәбә, эремчек, әйрән* һ.б. Татар ашлары арасында сөттән әзерләнгән ризыклар элек-электән зур урын алып торган. *Сөт*не шул килеш кенә сирәк кулланганнар, аны чәйгә салып эчкәннәр яисә ашамлыклар әзерләгәндә файдаланганнар. Сөттән *май* язганнар, *сөзмә, эремчек, катык, каймак, корт (тура)* ясаганнар, катыкны әчетеп *кәрчемә* иткәннәр. Татарлар ясаган *атланмай* бөтен тирә-юньдә дан тоткан. *Йомырка*ны каты итеп тә, чиле-пешле итеп тә пешергәннәр, ашка салганнар, *тәбә* әзерләгәннәр. Сабантуй вакытларында ул традицион ашамлык саналган.

5. Ярма, яшелчә ризыклары атамалары: *боламык, ботка, кәлҗемә, пылау, салат* һ.б. Татар халкы элек-электән иген игкән, шуңа күрә ярмадан төрле ризыклар әзерләгәннәр: *ботка*лар пешергәннәр, бодай, арыш

бөртекләрен кыздырып (*куырмач*) ашаганнар. Яшелчәләрне татарлар күп кулланмаган, ә XIX гасыр ахырыннан *бәрәңге* ризыклар арасында төп урынны алган, аның үзен генә дә, төрле ашларга кушып та пешергәннәр, *боламыг*ыннан юка гына кәтлитләр – *кәлҗемә* ясаганнар. Яшелчәләрне күбрәк камыр ризыклары эченә салганнар һәм башка ашамлыклар янына биргәннәр. Бигрәк тә *кабак, чөгендер, суган, кишер, ачы торма* кебек яшелчәләр күп кулланылган.

6. Камыр ризыкларын белдерә торган сүзләр: *бавырсак, белен, бәлеш, бөккән, гөбәдия, дучмак, икмәк, ипи, кабартма, калач, кактөш, камыр, катлама, коймак, кызартма, кыстыбый, кәтермәч, көлчә, кумәч, күптермә, ләвәш, паштет, пәрәмәч, сумса, талкан, тәбикмәк, төш, шәнгә, юка, юача, өчпочмак* һ.б. Татар халкы камыр ашларын электән яратып әзерләгән. Үзенең формасы, әзерләү рәвеше һәм эченә салына торган әйберләр төрлелеге ягыннан камыр ашлары бик үзенчәлекле. Аларны ачы һәм төче камырдан әзерлиләр, кайберләрен сыек (*коймак, белен*), икенчеләрен куе яки каты камырдан (*кабартма, паштет, бәлеш* һ.б.) пешерәләр. *Гөбәдия, бәлеш, пәрәмәч* һәм хәзерге вакытта киң таралган *өчпочмак* аерым урын алып тора, алар күп вакытта икенче аш итеп бирелә. Кайбер ризыкларның эченә ит белән бәрәңге, кайберләренә ярма, эремчек, корт, җиләк-җимеш салалар. Элек юлга чыгасы кешенең биштәренә *бавырсак, юка, төче кумәч* тыкканнар.

7. Чәй ризыклары: *кайнатма, как, кош теле, кәләвә, күбек, урама, пәхләвә, талкыш кәләвә, хәлвә, чәк-чәк, әлбә* һ.б. Татар халкы онга май, бал кебек әйберләр кушып, чәй янына татлы ашамлыклар әзерләгән. Бу ризыкларны туй өстәленә дә куйганнар. Бу ашамлыклар, гадәттә, табынны бизәп тора, шуңа күрә аларны төрлечә сырлап, матурлап ясыйлар. Элек туй яки башка бәйрәм табынына җиләк-җимештән яки балдан *ширбәт* ясаганнар. Хатын-кызга бала тапканнан соң *әлбә* китергәннәр. Чәйне *шикәр* кабып, *как* һәм төрле кипкән җимешләр салып эчкәннәр.

Хәзерге вакытта традицион туклану культурасы онытыла бара. Милли ризыклар ритуал дәрәҗәсендә әзерләүне, күп вакытны таләп итү сәбәпле, кешеләр тиз әзерләнә торган ризыкларга өстенлек бирә. Ашамлыкларның үзләре белән аларга бәйле лексик берәмлекләр дә шул сәбәпле юкка чыгу алдында. Халыкларның этник үзенчәлекләре бетеп барган бүгенге көндә милли ризык атамаларын, аларны әзерләү ысулларын өйрәнү, саклап калу гаять әһәмиятле.

Тел белемендә кием-салым атамалары да галимнәрнең күптәннән күз уңында. Төрле телләрнең әлеге төркемгә караган сүзләрен тикшерүгә багышланган хезмәтләр гаҗәеп күп.

Татар теленең көнкүреш лексикасының бу төркеме, яисә кайбер берәмлекләре җентекле тикшерелгән. Мәсәлән, Л.Ш.Арсланов, Ф.С.Баязитова, Н.Б.Борһанова, Л.Т.Мәхмүтова, Д.Б.Рамазанова, Р.К.Рәхимова, З.Р.Садыйкова, Т.Х.Хәйретдинова, Ф.Ю.Юсупов һ.б. хезмәтләрендә кием-салым атамалары теге яки бу аспектта каралган [21: 7]. С.В.Суслова тикшеренүләрендә татар костюмы тарихи-этнографик күзлектән яктыртылган [22]; Ф.Ф.Гулова китабында милли татар аяк киемнәре тире мозаикасы сәнгатенә бәйләп өйрәнелгән [23].

Кием-салым атамаларына игътибарның зур булуы очраклы түгел, чөнки бу предметлар, иң беренче чиратта, кешенең табигый ихтыяҗларын (салкыннан, эсседән, җил-яңгыр-кардан саклану һ.б.) канәгатьләндерә һәм кешелек тарихы дәвамында баеп-камилләшеп килә. Аларга нигезләнеп, халыкның тарихын, матди хәлен һәм статусын, рухи-мәдәни, икътисади бәйләнешларны, эстетик нормаларының үсеш-үзгәрешен һ.б. чамаларга була. Шул сәбәпле бу төркем предметларга һәм аларны белдергән сүзләргә тел белгечләре, этнографлар, тарихчылар, культурологлар һ.б. битараф түгел.

Татар телендә «кием» мәгънәсендәге лексик катлам гаять зур. Европаның кырыс географик һәм климатик шартларында киемнән башка тереклек итү мөмкин түгел: ул салкыннан һәм эсседән, яңгырдан һәм кардан, җилдән саклый; шул ук вакытта эстетик функция дә үти, ягъни кеше кием белән үзен тыштан берникадәр бизи дә. Димәк, кием-салым атамаларына өске кием атамаларын, баш һәм аяк-кул киемнәрен, аларның аерым өлешләрен, тукымаларны, тегү материалларын, бизәү детальләрен белдергән сүзләрне кертеп карарга була. Болар арасында татар традицион кием-салым атамалары игътибарны үзенә җәлеп итә. Аларда халыкның этник үзенчәлекләренә ишарә итә торган элементлар, халыкның күпгасырлык тәҗрибәсе, хуҗалык төзелеше һәм мәдәни дәрәҗәсе, физик-географик яшәү шартларына җайлашуы, эстетик күзаллаулары матди рәвештә чагыла. Р.Р.Җамалетдинов фикеренчә, «күпьеллык тарихы дәвамында традицион татар киеме

халыкның эстетик карашларын чагылдыра торган үзенчәлекле тел барлыкка китергән» [15: 155]. Татар халкының төрле төркемнәрендә төп киемнәр һәм аларның элементлары элек-электән гомуми булган. Мондый традицион кием-салымнар исемлеге шактый күләмле, кызганычка, аларның кайберләре инде онытылып бара, аерым төрләре татарның үткәнен чагылдырган фильм-спектакльләрнең, милли бәйрәмнәрнең аерылгысыз атрибуты, халык хәтерен саклаучы музейларның иң кыйммәтле экспонатлары буларак яшәүләрен дәвам итә.

Кием-салым атамаларын үз эчендә түбәндәге төркемчәләргә аерып карарга мөмкин.

1. Кием-салым предметларын гомумиләштереп атый торган сүзләр: *кием, күлмәк-ыштан. Кием* сүзе тукымадан, мехтан, күннән һ.б. материаллардан тегелгән, эшләнгән һәм тәнне каплау өчен хезмәт итә торган әйбер, һәртөрле киемнәрне атый. *Күлмәк-ыштан* сүзе дә бер кат өске киемне җыйнап атау өчен кулланыла.

2. Өске кием һәм аның аерым өлешләрен белдерә торган атамалар: *алъяпкыч, балак, билбау, бишмәт, итәк, камзул, каплама, кесә, кыса, камәр, күлмәк, пута, пәрәнҗә, толып, тун, халат, чадра, чалбар, чапан, чикмән, ыштан, эзәр, яка, әрмәк, җилән h.б.* Бу төркемдәге кайбер предметлар бүгенге көндә инде кулланылыштан төшеп калган. Мәсәлән, *бишмәт, әрмәк, җилән*не хәзер музейларда гына күрергә мөмкин. *Билбау, камәр, пута, эзәр* сүзләре киемнең бер үк элементын белдергәнгә, бу синонимик ояның кайберләре пассив сүзләр рәтенә күчкән.

3. Баш киемнәре: *башлык, бөркәнчек, бүрек, калпак, калфак, кәләпүш, кәпәч, көрәпәлә, тастар, түбәтәй, чалма, фәс, шәл, шәльяулык, эшләпә, яулык* һ.б. Бу баш киемнәре арасында *кашбау* – алгы ягы сәйлән, энҗе, асылташлар белән бизәлгән, тасма яки такыясыман хатын-кыз баш кием, *тастар* – кияүгә китәсе кызлар башларына сарып йөри торган озынча ак киндер яулык, гомумән, тарихта калган. *Кәпәч* – түбәтәй, *көрәпәлә* – «кайбер өске киемнәрнең очлы башлыгы, капюшон» бүгенге көндә дә киелә торган баш киемнәренең искергән атамаларын белдерәләр. *Чалма* һәм *фәс*, дини атрибут буларак, хәзер дә кулланылышта йөри.

4. Аяк киемнәре һәм аның өлешләрен атый торган сүзләр: *аякчу, балтыр, башмак, будыргыч, бәйләвеч, итек, ката, киндерә, кунын, кәвеш, кутәртмә, оек, оекбаш, олтан, олтырак, оектоткыч, чабата, читек, чүәк, ыштыр* һ.б. Бу төркемдәге кайбер предметлар шулай ук кулланылыштан төшеп калган: *аякчу* – аяк чолгавы, *будыргыч* – тарттырып, будырып куя торган сузылмалы (резинкалы) тасма, *кутәртмә* – язын яки көзен чабатага су үтмәсен өчен, аның астына беркетелгән ике агач шакмак, *оектоткыч* – оек будыргыч, *чабата* – юкә, карама каерылары яки каешның телемле тасмаларыннан үреп ясалган баулы сай аяк киеме, *ыштыр* – киндер, фланель яки башка тукыма кисәгеннән ясалган аяк чолгавы һ.б.

5. Кулга киелә торган кием атамалары: *бишбармак, бияләй*. Кулны салкыннан саклау өчен, кешелек әлегә кадәр болардан да уңайлырак әйберләр уйлап таба алмаган, *бишбармак* сүзе хәзерге көндә пассиврак кулланыла, аерым җирле сөйләшләрдә генә очрый, аның урынына алынма перчатка сүзе йөри.

6. Бизәнү әйберләре атамалары: *алка, балдак, беләзек, изү, ишмә, йөзек, кадавыч, каеш, кулбау, муенса, мәрҗән, тарак, тасма, хәситә, чулпы, чылбыр, чәчкап, чәчүргеч, җилпәзә* һ.б. *Изү* – татар хатын-кызларының, төрле төстәге тасмаларны изү тирәли тегеп, укалар белән чигеп, тәңкәләр һ.б. зиннәтләр белән бизәп эшләнгән, күлмәк якасыннан алып билгә кадәр бөтен күкрәкне каплый һәм бизәнү өчен күлмәк өстеннән киелә торган күкрәкчәсе, *ишмә* – тимер яки бакыр чыбыкка көмеш җепләр урап ясалган беләзек, *хәситә* – күлмәк өстеннән киелә торган, алтын-көмеш акчалар һәм ука асылташлар белән бизәлгән күкрәкчә, *чулпы* – чәч толымына кушып үрелә торган тасма очына тагылган бизәнү әйберсе, *чәчкап* – элек татар хатын-кызларының чәч толымнарын каплап йөртә торган, тәңкәләр белән бизәлгән, тукымалардан ясалган баш киеменә өстәмә әйбер. Бу бизәнгечләрне хәзер хатын-кызлар инде кулланмый, аларны фольклор ансамбльләренең чыгышларында гына күрергә мөмкин. *Беләзек, кулбау* сүзләрен *браслет* сүзе алыштырды, *кадавыч* сүзенең дә русча вариантлары (заколка, приколка, шпилька) активрак кулланыла.

7. Кием-салымны бизәүгә бәйле терминнар: *аса, бизәк, бөрмә, зияк, инеч, кайма, каптырма, каптыргыч, күчергеч, маң, сәдәп, сәйлән, төймә, чачак, чигеш, чуптар, чәкән, чәмчә, чүпләм, әдеп, җияк* һ.б. Бу төркемгә кергән сүзләр арасында тегүче, чигүче һөнәрләренә генә хас булганнары шактый, ә *каптырма, каптыргыч, сәдәп, төймә* кебек сүзләр хәзер дә гомумкулланылышка ия.

Һәр халыкның теле – аның сүзләрдә чагылыш тапкан тарихи хәтере, ул халык байлыгын, аның үткәнен түкми-чәчми киләчәк буыннар өчен саклый. Бу кием-салым атамаларына да карый. Сүзлек составының XXI гасыр башына кадәр килеп җиткән «кием-салым» төркемендә татар халкының милли һәм элеккеге кием атамаларыннан тыш (аларның да күбесе тарихи лексикага карый), халыкара кулланылышта йөргәннәре дә күп. Халыкның көнкүреш хәле яхшыру, җиңел сәнәгатьнең алга китүе, модaның үзгәреп торуы һәм халыкара статус алуы татарлар куллана торган бу төр предметларга тәэсир итми калмый: традицион киемнәр теге яки бу этноска нисбәтсез әйберләр белән алышына.

Матди мәдәният кыйммәтләре арасында йорт-торак белән бәйләнгән төркем мөһим урын алып тора. Торак, яшәү корылмалары – тарихи категорияләр, һәм алар хуҗалык эшчәнлеге һәм халыкның матди мәдәнияте белән тыгыз бәйләнештә. Иҗтимагый-социаль шартлар үзгәрү белән корылма кыяфәтләре дә үзгәрә. «Торак» лексик-тематик төркемен тикшерү халыкның үткәнен, этнографиясен, башка халыклар белән бәйләнешен өйрәнүгә мөмкинлек бирә [24: 3]. Татар этнографларының хезмәтләрендә бу тематик төркем турында бай материал тупланган: Р.Г.Мөхәммәдова мишәр татарларына [14], Й.Мөхәммәтшин керәшен татарларына хас традицион торак типларын барлаган [25], Н.Халиков Идел буе һәм Урал татарларының хуҗалыгындагы терлекләрне җәен һәм кышын асрау өчен төзелгән корылмаларга тасвирлама биргән [26].

Тикшеренүчеләрнең хезмәтләреннән күренгәнчә, татар халкында корылмалар төрле материаллардан эшләнгән: кирпеч, таш, бүрәнә, гадирәк корылмалар такта яки читәннән генә дә корылган. Ләкин озак еллар дәвамында агач төп төзелеш материалы булып килгән [27: 106]. Болгар территориясендә үк йортларны, мәчет, мунчаларны имән бүрәнәләрдән эшләгәннәр. Балта эше ул вакытта беренче урындагы һөнәрләрдән саналган [28: 65]. Татарларда бүгенге көндә дә йортлар агачтан бизәкләп эшләнгән, төрле якты төсләргә буялган. Капка да, тактадан эшләнеп, баганаларга утыртылган, түбәсе ябулы, ачык буяулы олы һәм кече капка формасында күзаллана.

Татар телендә *йорт* һәм *өй* лексемалары синоним буларак йөрсә дә, аларның аермалы яклары да бар. *Йорт* бер нигез, гаилә әгъзалары яши торган торакны тулаем, ягъни янындагы барлык каралты-куралары, корылмалары белән тулаем атый. *Өй* исә таррак мәгънәдә, ешрак йортның эчке өлешен аңлата. Өй эчендә башкарылган эшләрне өй эшләре, ә инде йорт, каралты-кура тирәдәге хезмәтләрне йорт эшләре дип йөртү гадәте шуның белән аңлатыла.

Татар телендә «торак» тематик төркеме үз эчендә ваграк төркемчәләргә бүленә.

4. Каралты-кура төркемчәсенә караган лексемалар. *Каралты-кура* сүзенә килгәндә, *каралты* – хуҗалык корылмаларын аерым-аерым чагылдырса, *кура* – гомумиләштерүче атама. Димәк, *каралты-кура* барлык хуҗалыкны, андагы корылмаларны гомумиләштерә. Бу төркемгә түбәндәге сүзләр керә: *койма, капка, абзар, келәт, мунча* һ.б.

Крестьян каралтысы татарларда алгы якта – ишегалдына һәм арткы якта бакчага, ындырга бүленә. Беренче өлештә йорт, келәт, терлек абзарлары, хуҗалык корылмалары урнаша, икенчесен яшелчә бакчасы, мунча, әвенлек, печәнлек һәм ындыр табагы алып тора [29: 151].

Татарлар каралтыны *койма* белән уратып ала һәм *капка* керү-чыгу юлы булып тора. Койма территорияне аерып, шәхси тормыш җирлеге булдыру өчен мөһим. Капка тышкы дөнья белән хуҗалык тормышы арасында арадашчы буларак хезмәт итә. *Ишегалды* атамасының мәгънәсе киң, ул ишек алдындагы урынны гына түгел, ә бәлки койма белән әйләндереп алынган йорт территориясен чагылдыра. Борынгыдан ук терлек үрчетү белән шөгыльләнгән татарлар тормышында *абзар* аерым әһәмиятле урын алып тора, алар нинди терлек асралуга бәйле рәвештә төрләргә аерыла. *Келәт* күпчелек очракларда ашлык, он саклау өчен хезмәт итсә дә, ул хәтта торак буларак кулланылырга да мөмкин булган. *Мунча* пөхтәлек, чисталык яратучы татарлар өчен аеруча кыйммәткә ия. Болгар чорындагы хәммам-мунчалар, хәзерге сауналарга караганда, күпкә затлырак һәм шифалырак булган. Татар халкында *ак мунча* һәм *кара мунча* дигән бүленеш тә яшәгән.

5. Өйнең тышкы төзелешенә караган сүзләр: *нигез, бура, ишегалды, түбә, морҗа* һ.б.

Татарлар яшәгән йорт, аеруча хәллерәк кешеләрдә, үзенең купшылыгы һәм архитектура бизәлеш үзенчәлекләре белән аерылып торган. Тәрәзә йөзлекләре дә матур бизәлешләре белән милли хосусиятләрне чагылдыра [30: 83-84].

Татар халкы элек-электән йорт салып керүгә зур әһәмият биргән. Торак булдырасы урында башта *нигез* күтәрелгән, аңа йорт *бура-*

сы ныгытылган. Нигез эреле-ваклы ташларны балчык яки ком измәсе белән катыштырып эшләнгән. *Бура* һәм *нигез* – төзелешнең үзәге. *Бура* төрле материалдан (агач, кирпеч, таш һ.б.) эшләнергә мөмкин, ләкин татарларда ул, башлыча, бүрәнәләрдән бурала. Нигез өстенә бүрәнәләрдән бура өелә, аннан йортның *түбә*се ябыла, өй түбәсендә, төтен чыгу юлы буларак, *морҗа* калкып чыга. *Түбә, морҗа* атамаларның күпмәгънәлелеккә ия булуы, халык авыз иҗатында еш кулланылуы аларның әһәмиятен тагын бер кат искәртә. *Өйалды* җылытылмый һәм өйнең алдында түгел, ә керү ягында урнаша, бүрәнә буралардан яки такталардан корыла, агач идән түшәлә һәм түшәмсез була. Өйнең төзелешенә караган берәмлекләр. Боларга *тәрәзә, ишек, бусага, тупса, түшәм* һ.б. мисалга китерергә мөмкин.

*Тәрәзәләр* – өй эчен тышкы дөнья белән бәйләү, яктылык кертү чарасы. Татар халкы тәрәзәләрне өйгә ямь бирү, җанландыру чарасы итеп кабул иткән, аларга бизәкле, матур пәрдәләр элгән, тәрәзә төпләренә гөлләр утырткан. Йорт эченә кереп-чыгып йөрү максатыннан уелган *ишек* тә мөһим мәдәни кыйммәтләрнең берсе, татар лингвомәдәниятендә *ишек* лексемасы кунакчыллык, ачык йөз яки тар күңеллелек белән бәйләнгән. *Бусага, тупса* төшенчәләре ишек белән турыдан-туры тоташкан. *Түшәм* лексемасы да – үзенчәлекле берәмлек. Әлеге атама кергән фразеологизмнар, күчерелмә мәгънәләр телебездә гаять еш очрый. Атаманың төп мәгънәсе – бинаның, өйнең такталардан яки плитәдән эшләнгән эчке капламасы.

Татар телендә өйнең эчтән бүленеш үзенчәлекләрен *түр, аралык, почмак як, морҗа, мич, мич башы, кече як* кебек сүзләр чагылдыра.

*Түр* – бүлмәнең ишеккә каршы урнашкан ягы – гаиләнең иң хөрмәтле әгъзалары һәм кунаклар урыны. *Мич* татар өендә әһәмиятле урын тоткан: анда ризык әзерләгәннәр, аның ярдәмендә өйне җылытканнар, мич башында йоклау урыны булган һ.б. Мичнең тагын бер вазифасы – ул өйне берничә өлешкә бүлә: *мич алды / мич каршы* – мичнең авызы урнашкан ягы, гадәттә өйнең бу өлешендә ашарга пешергәннәр, әзер ризыкны табынга чыгарырга әзерләгәннәр. *Почмак як* күбрәк мич алдындагы урынны атау өчен кулланыла. Өйнең кечкенә ягы – *кече як* – шулай ук ризык әзерләнә торган бүлмә.

6. Өйнең эчке бизәлеш элементлары. Шуны искәртеп үтү мөһим: татарлар өйнең эчке күренешенә зур игътибар бирсәләр дә, элек йорт җиһазлары күп булмаган. Әмма җиһаз азлыгы диварларга эленгән кул эшләнмәләре, чигүле әйберләр белән тулыландырылган.

Татар өенең эчке күренешенә караган тематик төркемдә *мич, морҗа, сәке, урын, өстәл, шүрлек, көзге, чаршау, чыбылдык* лексемалары урын ала [31: 98]. Гаилә әгъзаларының тормышын уңайлы-җайлы итү бу детальләрнең төп вазифасы булып тора. Дөрестән дә, утрак тормышның язылмаган кануннары йортта билгеле бер җиһазларның, йорт төзелешенә караган өстәмә элементларның булуын таләп итә.

Элекке татар өйләрендә тагын бер әһәмиятле элемент – *сәке* – калын такталардан гыйбарәт булып, идәннән ярты метр чамасы биеклектә җәеп эшләнгән утыру-яту урыны. Бу предмет узган гасыр татар өендә күп төрле вазифалар үтәгән: анда утырганнар, ашаганнар, йоклаганнар, көндез кечкенә балалар уйнаган һ.б. *Сандык* күп кенә этнографлар тарафыннан татар өендәге типик элемент буларак тасвирлана. Ул кием, чүпрәк-чапрактан эшләнгән әйберләрне, кызларның бирнәсен һ.б. саклау предметы булып хезмәт иткән. Шуңа күрә аның төрле рәвештә эшләнгәннәре (тимерле сандык, агач сандык, кәрзин сандык һ.б.) кулланылган. *Өстәл* – өстенә нәрсә дә булса кую яки анда эшләү, ашау-эчү өчен терәккә яки аякларга беркетелгән яссы өслек. Ул Идел-Урал татарлары тормышына XIX гасыр ахыры – XX йөз башында килеп керә [32: 51]. Өстәл янына утырып эшләү өчен кулланыла торган *урындыклар* татар өендә шактый соң пәйда булган. *Сәгать* – тормыш-көнкүрешнең мөһим элементы, татарлар аны стенага элгәннәр, «герле», «күкеле» төрләрен аеруча яратканнар.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, «йорт-торак» компонентлары тормыш итү, хуҗалык алып бару өчен зур әһәмияткә ия. Телдә әлеге атамаларны саклап калу, аларны буыннан-буынга җиткерү мөһим.

Аралашу чарасы буларак тел иҗтимагый тормыш белән бик тыгыз бәйләнгән. Җәмгыятьтәге үзгәрешләр телнең сүзлек составына зур йогынты ясый. Теге яки бу күренешләрнең, предметларның кулланылыштан төшеп калуы яки, киресенчә, барлыкка килүе телдә дә чагыла.

Соңгы елларда җәмгыятьтә күзәтелгән үзгәрешләр моңарчы күрелмәгән күләмдә матди мәдәният предметларының һәм аларны ата-

ган сүзләрнең гомумкулланылыштан әкренләп төшеп калуына китерде. Шул ук вакытта яңа әйберләр һәм аларның атамалары да тормышыбызга ташкын булып килеп керде. Бу хәл милләтләр арасындагы, шул исәптән милли мәдәниятләрдәге чикләрне юкка чыгарып, аермаларны киметеп, телләрнең лексикасында да, халыкларның тормыш-көнкүрешендә дә охшашлыклар барлыкка китерә. Әмма тел лексикасының бер катламы, тормыш итү өчен мөһим, беркайчан да әһәмиятен югалтмый торган төшенчә-күренешләрне атау сәбәпле, гасырлар буена кулланылышта калалар һәм татар халкының милли менталитетын билгели торган күрсәткечләр булып торалар. Аларны барлау һәм аерым атамаларны җентекләп өйрәнү татар матди һәм рухи мәдәнияте формалашу, үсү һәм камилләшү тарихына яңа сәхифәләр өстәячәк.

**Әдәбият**


1. *Толстой Н.И.* Язык и народная культура. Очерки по славянской мифологии и этнолингвистике. М.: Индрик, 1995. 518 с.
2. *Ахметьянов Р.Г.* Общая лексика духовной культуры народов Среднего Поволжья. М., 1981. 144 с.
3. *Yusupova A.S., Galiullina G. R., Denmukhametova E.N.* Representation of national mentality in Turkic-Tatar vocabulary. Life Sci J 2014;11(7): 506-508
4. *Степанов Ю.С.* Константы: Словарь русской культуры: изд-е 3-е, испр. и доп. М.: Академический проект, 2004. 992 с.
5. *Набиуллина Г.А., Денмухаметова Э.Н., Мугтасимова Г.Р.* Лексика и синтаксис татарских пословиц // Филология и культура. Philology and Culture. 2014. №4(38). – С. 159-163.
6. Древнетюркский словарь. Л.: Ленинградское отделение «Наука», 1969. 676 с.
7. *Нуриева Ф.Ш.* Названия пищи в тюркоязычных письменных памятниках золотоордынского периода // Филологические науки. 2. Вопросы теории и практики. 2015. № 7-1 (49). С. 143-146.
8. *Кадирова* Э.Х. Поэмы Мухамедьяра «Тухфа-и мардан» и «Нур-и-содур»: лексика. Казань: Дом печати, 2001. 232 с.
9. *Юсупова А.Ш.* Двуязычная лексикография татарского языка XIX века. Казань: Изд-во Казанск.гос. ун-та, 2008. 410 с.
10. *Саттарова М.Р., Замалетдинова Г.Ф.* Роль этнокультуры в формировании национального самосознания // Филология и культура. Philology and Culture. 2012. №3(29). С. 320-322.
11. *Хайрутдинова Т.Х.* Названия пищи в татарском языке. Казань, 1993. 142 с.
12. *Мөгътәсимова Г.Р.* Татар халык мәкальләренең лексикасы. Казан: В.И.Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт ун-ты, 2005. 192 б.
13. *Баязитова Ф.С.* Аш-су һәм халык традицияләре лексикасы. Казан: Дом печати, 2007. 480 б.
14. *Мухамедова Р.Г.* Татары-мишари. Историко-этнографическое исследование. Казань: Магариф. 2008. 295 с.
15. *Замалетдинов Р.Р.* Теоретические и прикладные аспекты татарской лингвокультурологии. Казань: Магариф, 2009. 351 с.
16. *Тарасова Ф.Х.* Паремии с компонентом «пища» в татарском, русском и английском языках. Казань: РИЦ, 2012. 304 с.
17. *Замалетдинов Р.Р., Нурмөхәммәтова Р.С.* Татар теленең этнокультура сүзлеге: матди мәдәният лексикасы. Казан: Отечество, 2012. 146 б.
18. *Замалетдинов Р.Р., Нурмухаметова Р.С.* Материальная культура в словарях татарского языка XX-XXI веков (на примере лексики пищи) // Филология и культура. Philology and Culture. 2012. №3 (29). С.51-55.
19. *Нурмухаметова Р.С.* Развитие кулинарной лексики татарского языка XX – начала XXI века // Филология и культура. Philology and Culture. 2013. № 4 (34). С. 86-91.
20. *Нурмухаметова Р.С.* Влияние внешней среды на формирование и функционирование лексики пищи татарского языка // Филология и культура. Philology and Culture. 2014. № 4 (38). С. 164-169.
21. *Рамазанова Д.Б.* Названия одежды и украшений в татарском языке в ареальном аспекте. Казань: Мастер-Лайн, 2002. 354 с.
22. *Суслова С.В.* История костюма тюркских народов (этнографическое исследование татарской народной одежды). Астана: Сарыарка, 2011. 286 с.
23. *Гулова Ф.Ф.* Татарская национальная обувь: Искусство кожаной мозаики. Казань: Татар. кн. изд-во, 1983. 47 с.
24. *Садыкова З.Р.* Названия хозяйственных построек и инвентаря в татарском языке. Казань: Печатный Двор, 2003. 212 б.
25. *Мухаметшин Ю.Г.* Татары-кряшены. Историко-этнографическое исследование материальной культуры. Середина XIX – начало XX в. М.: Наука, 1977. 184 с.
26. *Халиков Н.А.* Хозяйство татар Поволжья и Урала (середина XIX – начало XX вв.). Казань: ИЯЛИ, 1995. 235 с.
27. *Валеев Ф.Х.* Народное декоративное искусство Татарстана. Казань: 1984. 171 с.
28. *Валеев Ф.Х., Валеева-Сулейманова Г.Ф.* Древнее Искусство Татарии. Казань, 1987. 195 с.
29. *Җамалетдинов Р.Р.* Тел һәм мәдәният: Татар лингвокультурологиясе нигезләре. Казан: Мәгариф, 2006. 351 б.
30. Этнография татарского народа / Под ред. Д.М.Исхакова. Казань: Магариф, 2004. 287 с.
31. *Зиангирова Э.М.* Татарская лингвокультурология: функционирование концептов «өй» и «йорт» (на материале произведений

М.Магдеева). Казань: Казан. гос. ун-т им.В.И.Ульянова-Ленина, 2007. 217 с.

32. *Сулейманова Д.* Интерьер татарского дома: истоки и развитие. Казань: Татар. кн. изд-во, 2010. 141 с.

# ЭТНОКУЛЬТУРНАЯ ЛЕКСИКА ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА

**Раушания Сагдатзяновна Нурмухаметова,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420021, г. Казан, ул. Татарстан, д. 2,
rsagadat@yandex.ru.

В последние годы в лингвистических исследованиях основное место занимает изучение лексики, отражающей культурно-национальную специфику народа, представления носителей языка об окружающем мире. Они характерны для каждого языка, и знакомство с ними расширяет мировоззрение человека, формирует интерес к культуре этноса. Данная статья посвящается изучению важнейшего пласта словарного состава языка – этнокультурной лексики. Рассматриваются лексические единицы материальной культуры татарского языка, а именно: названия пищи, одежды и жилища. Дается краткий обзор тематических групп, описываются некоторые особенности изучаемых явлений. В названиях предметов материальной культуры находит отражение жизненный опыт народа. Изучение такой культурно-маркированной лексики позволяет возродить некоторые забытые традиции, дает возможность находить общие и специфические элементы в разных этнических культурах.

**Ключевые слова:** татарский язык, этнокультурная лексика, лексика материальной культуры, лексико-тематическая группа.